| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ**<br>**Октябрьского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района**<br>422580, пос. Октябрьский, ул. Центральная, д.7<br>тел: (8-84379) 31-4-27 факс: (8-84379) 31-4-27 | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**ЮГАРЫ ОСЛАН муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ**<br>422580, Октябрьский авылы, Үзәк ур., 7 нчы йорт<br>тел: (8-84379) 31-4-27 факс: (8-84379) 31-4-27 |


КАРАР

2015 елның 24 апреле № 51-255

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 26 статьясы нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын (кушымта) расларга.
2. «Волжская новь» газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге советы рәисе Азизов Шамил Рәмис улына йөкләргә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш.Р. Азизов

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль
районының Октябрьский авыл
җирлеге Советының 24 апрель
2015 ел № 51-255 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары график сурәтләү схемасы

| |
|---|
| 1 нче бермандатлы Октябрьский сайлау округы |
| Округка керә: Октябрьский авылы, Үзәк урамда 1 нче йорттан 4 нче йортка кадәр, Юбилейная ур., , Весенняя ур. Сайлаучылар саны 88 кеше. |
| 2 нче бер мандатлы Октябрьский сайлау округы |
| Округка керә: Октябрьский авылы, Үзәк урам, №5, 6 йортлар; Яшьләр урамы. Сайлаучылар саны 84 кеше |
| 3 нче бермандатлы Октябрьский сайлау округы |
| Округка керә: Октябрьский ав., Мәктәп ур., Школьная ур., Лесная ур., 1 нче йорттан 11 йортка кадәр. Сайлаучылар саны 85 кеше |
| 4 нче бер мандатлы Октябрьский сайлау округы |
| Округка керә: Октябрьский ав.,Урман урамындагы №12 йорттан №16 йортка кадәр, Үзәк урам, № 9 йорттан 20 йортка кадәр, Южная урамы, 6 нчы йорттан 14 йортка кадәр. Сайлаучылар саны 89 кеше |
| 5 нче Яңа Болгар бермандатлы сайлау округы |
| Округка керә: Октябрьский ав., Көньяк ур., 1 нче йорттан 4 йортка кадәр, Яңа Болгар авылы. Сайлаучылар саны 84 кеше |
| 6 нчы Ключищи бермандатлы сайлау округы |
| Округка Ключищи авылы керә. Сайлаучылар саны 121 кеше |
| 7 нче Матюшино бермандатлы сайлау округы |
| Округка Матюшино авылы керә. Сайлаучылар саны 48 кеше |

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары график сурәтләү схемасы




| Округ номеры | Округ исеме |
|---|---|
| 1 | Октябрьский |
| 2 | Октябрьский |
| 3 | Октябрьский |
| 4 | Октябрьский |
| 5 | Яңа Болгар |
| 6 | Ключищи |
| 7 | Матюшино |